РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

27.10.2020 с. Куралово 45

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004нче елның 24нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә, Куралово авыл җирлегенең Рус Бурнашы авылы гражданнар җыенында 2020нче елның 20нче октябрендә кабул ителгән 1нче номерлы карарны тормышка ашыру максатында, Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе Т. Ю. Тимиряева

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының
2002нче елның 27нче октябреннән
45нче номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар тарафыннан, гражданнар җыеннарында катнашуларына һәм тавыш бирүдә катнашкан мөнәсәбәтләренә карамастан, үзара салым акчаларын түләү 2021нче елның 1нче гыйнварыннан 2021нче елның 31нче мартына кадәр башкарыла.

3. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша почтадан акча күчерү белән тормышка ашыру, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек - ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.